ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2020 ел Баулы шәһәре №217

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 28 февралендәге 35 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр уздыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (31.07.2020 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 28 февралендәге 35 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр уздыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларга (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның, дәүләт контроле (күзәтчелеге)

органнары, мондый юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң муниципаль контроль органнары хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2нче өлешенең 2нче пунктының «а», «б» һәм «г» пунктчаларында, 2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә мондый юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.»;

7нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәҗбүри таләпләр яисә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәмәү ачыкланганда, тикшерү уздырган муниципаль контроль органы, Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә, түбәндәгеләр тиеш:

1) юридик затка, индивидуаль эшкуарга, ачыкланган хокук бозуларны бетерү срокларын күрсәтеп, һәм (яисә) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренә), физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмау чараларын, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында күрсәтмә бирергә;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерүне, аларны булдырмауны, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү ихтималын булдырмый калуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) зыян китерүне, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтүне тикшереп тору чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрергә.»;

12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Язма шикаятьтә мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

йә язма мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органының исеме, йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле вазыйфаи затның вазыйфасы;

гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) йә юридик затның исеме, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә;

шикаятьнең асылы;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең имзасы, мөһере (булган очракта), датасы.

Кирәк була калса, үзенең дәлилләрен раслау өчен мөрәҗәгать итүче язма мөрәҗәгатькә документлар һәм материалларны йә аларның күчермәләрен терки.

Электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән шикаять әлеге регламентта билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Шикаятьтә мәҗбүри тәртиптә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) яисә юридик затның исеме, почта адресы күрсәтелә, аның буенча җавап җибәрелергә, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш. Мөрәҗәгать итүче мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә кушып бирергә хокуклы.»;

12.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең таләпләрен канәгатьләндерү турында йә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителә, карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятькә җавап электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән электрон почта адресы буенча һәм җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча һәм язма рәвештә юллана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров